| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ**
**23.04.2018**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 187**

«2016-2026 елларга «Ишегалды стандарты» программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Карары проектын килештерү хакында

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалык департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Р. А. Гыйрфанов мәгълүматны тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, 2016-2026 елларга «Ишегалды стандарты» программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында, Зеленодольск шәһәре Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «2016-2026 елларга «Ишегалды стандарты» программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Карары проектын килештерергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск шәһәр Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**